**УПРАВЛЕНИЕ ПО ОХРАНЕ И ИСПОЛЬЗОВАНИЮ ОБЪЕКТОВ**
ЖИВОТНОГО МИРА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫ**Ң
ХАЙВАННАР ДӨНЬЯСЫ
ОБЪЕКТЛАРЫН САКЛАУ
ҺӘМ АЛАРДАН
ФАЙДАЛАНУ ИДАРӘСЕ

---

**Приказ** **Боерык**

«___» ноября 2015 года г. Казань № 150-од

Татарстан Республикасының хайваннар дөньясы
объектларын саклау һәм файдалану идарәсе
карамагындагы Иҗтимагый Киңәшмә турында
Кагыйдәнамәне раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 18.11.2010 елдан 906 номерлы “Министерство ( Идарә) карамагындагы иҗтимагый киңәшмә турында”гы карары белән тәңгәл килеп, **боерам:**

1. Кушымтада бирелгән Татарстан Республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану идарәсе карамагындагы Иҗтимагый Киңәшмә турында Кагыйдәнамәне расларга.
2. Татарстан Республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану идарәсенең хайваннар дөньясы объектларын куллануны тикшерүче бүлекнең алдынгы киңәшчесенә (Фугин В.В.) бу боерыкны дәүләт рәсмиләштерүенә Татарстан Республикасының Юстиция министрлыгына юнәлтергә.
3. Бу Боерыкның үтәлүен тикшерүне Татарстан Республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану идарәсе башлыгының урынбасарына Ю.Б. Матвеевка тапшырырга.

Идарә башлыгы Ф.С.Батков

Татарстан Республикасының
хайваннар дөньясы объектларын
саклау һәм файдалану Идарәсенең
2015 елның 10 ноябреннән 150-од
номерлы боерыгы белән расланган

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ХАЙВАННАР ДӨНЬЯСЫ ОБЪЕКТЛАРЫН САКЛАУ ҺӘМ ФАЙДАЛАНУ ИДАРӘСЕ КАРАМАГЫНДАГЫ ИҖТИМАГЫЙ КИҢӘШМӘ ТУРЫНДА КАГЫЙДӘНАМӘ

## 1. Гомуми кагыйдәләр

1.1. Бу кагыйдәнамә Татарстан Республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану идарәсе карамагындагы иҗтимагый киңәшмәнең максатларын, мәсьәләләрен һәм эшчәнлек оештыру нигезләрен билгели ( алга таба – Киңәшмә).

1.2. Киңәшмә, хайваннар дөньясы объектларын һәм аларның яшәү тирәлеген саклау һәм файдалану өлкәсендә булган мәсьәләләрне карый торган Татарстан Республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану идарәсе (алга таба – Идарә) карамагындагы даими рәвештә эшли торган киңәшмә әгъзасы булып килә.

1.3. Киңәшмәнең карарлары рекомендация рәвешендә биреләләр.

1.4. Киңәшмә үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясе, федераль конституция кануннары, федераль кануннар, Россия Федерациясе Президенты боерыклары, Татарстан Республикасы Конституциясе ,Татарстан Республикасы кануннары , Татарстан Республикасы Президенты боерыклары, Татарстан Республикасы хөкүмәте боерыклары һәм бу Кагыйдәнамә белән куллана.

1.5. Киңәшмә әгъзалары үзләренең бурычларын иҗтимагый башлангычта үтиләр.

1.6. Киңәшмә эшчәнлеге ирекле нигездә, ачыклык һәм партнерлык принципларында, гражданлык җәмгыяте институты вәкилләренең, дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә әгъзаларының, массакүләм мәгълүмат чараларының үзара кызыксынуында төзелә.

1.7. Иҗтимагый киңәшмәнең катнашмасы һәм саны Идарә башлыгы боерыгы белән раслана.

## 2. Киңәшмәнең максатлары, мәсьәләләре һәм вәкаләтләре.

2.1. Киңәшмә түбәндәге максатлар белән булдырыла:

хайваннар дөньясы объектларын һәм аларның яшәү тирәлеген саклау һәм файдалану өлкәсендә дәүләт сәясәтен формалаштырганда һәм тормышка ашырганда, Россия Федерациясе гражданнарының ихтыяҗларын хисапка алу, Россия Федерациясе гражданнарының һәм иҗтимагый оешмаларның хокукларын һәм иреген яклау;

хайваннар дөньясы объектларын һәм аларның яшәү тирәлеген саклау һәм файдалану өлкәсенә караган, дәүләт сәясәте сораулары буенча төп юнәлешләрне эшкәртергә иҗтимагый, һөнәри һәм иҗади оешмаларны чакыру. Идарә эшчәнлегенең ачыклык һәм хәбәрдарлык принципларын тормышка ашыру.

Идарә белән күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләренең сыйфатын иҗтимагый тикшерүне көчәйтү, хайваннар дөньясы объектларын һәм аларның яшәү тирәлеген саклау һәм файдалану өлкәсендә канунлык һәм һөнәрлек принципларын үстерү.

**2.2. Киңәшмәнең төп мәсьәләләре:**

Татарстан Республикасы территориясендә аучылык һәм биологик су байлыклары, хайваннар дөньясы объектларын һәм аларның яшәү тирәлеген саклау һәм файдалану өлкәсендә дәүләт сәясәтен камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерләү;

Татарстан Республикасы территориясендә аучылык һәм биологик су байлыклары, хайваннар дөньясы объектларын һәм аларның яшәү тирәлеген саклау һәм файдалану өлкәсендә норматив хокукый акт проектларына иҗтимагый экспертиза уздыру, шул санда Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте әгъзалары белән эшләнгән дәүләт программалары проектларын тикшерү;

Идарә белән карар кабул иткәндә җәмгыять фикерен хисапка алу җайланмасын камилләштерү;

Идарәнең төп эшчәнлек юнәлешләре буенча җәмәгатьчелекнең белемен күтәрү ;

2.3. Киңәшмәнең максатлары һәм мәсьәләләре, аның эш нәтиҗәләренә, ә шулай ук Россия Федерациясендә икъдисади, иҗтимагый һәм сәяси хәлгә карап үзгәрергә һәм тулыланырга мөмкин.

## 3. **Киңәшмә катнашмасы**

3.1. Идарә карамагындагы Киңәшмә, гражданнар, иҗтимагый оешмалар, ә шулай ук дәүләттән тыш коммерцияле булмаган оешмалар тәкъдимнәре нигезендә, рәис, рәис урынбасары, сәркатиб һәм Киңәшмә әгъзалары катнашмасында формалаштырыла. Киңәшмәнең аерым катнашмасы Идарә башлыгы белән раслана.

3.2. Киңәшмә катнашмасында ирекле рәвештә 10 кеше катнашу нигезендә формалаштырыла.

3.3. Киңәшмә катнашмасына гражданнар керә ала, шул санда иҗтимагый оешмалар вәкилләре һәм башка иҗтимагый юнәлешле коммерцияле булмаган оешмалар вәкилләре. Киңәшмә алдына куелган сорауларны чишү өчен кирәкле һөнәри сыйфатлары, шул санда туры килүче белеме, хайваннар дөньясы объектларын һәм аларның яшәү тирәлеген саклау һәм файдалану өлкәсендә булган эш тәҗрибәсе санала.

Киңәшмә катнашмасына, бу пуктның беренче кызыл юлында күрсәтелгән затлар белән беррәттән, Татарстан Республикасының Иҗтимагый палата белән тәкъдим ителгән затлар кертелә.Алар Киңәшмә катнашмасының яртысын тәшкил итәләр.

Иҗтимагый киңәшмә катнашмасына элек Россия Федерациясенең дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларын, Россия Федерациясенең дәүләт вазифаларын, Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең башка субъектларының дәүләт вазифаларын, муниципаль һәм муниципаль хезмәт вазифаларын алмаштырган затлар керергә мөмкин. Алар Киңәшмә катнашмасының гомуми санының биштән берен тәшкил итәргә мөмкин.

3.4. Иҗтимагый киңәшмә катнашмасына Россия Федерациясенең дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларын, Россия Федерациясенең дәүләт вазифаларын, Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең башка субъектларының дәүләт вазифаларын, муниципаль һәм муниципаль хезмәт вазифаларын алмаштыручы затлар, суд карары нигезендә эшкә яраксыз дип танылган затлар, гамәлдән чыкмаган яки өстеннән төшерелмәгән хөкемгә тартылуы булган затлар, ә шулай ук 2005 елның 4нче апреленнән 32-ФЗ номерлы "Россия Федерациясенең Иҗтимагый палатасы турында"гы Федераль канун белн тәңгәл килгән башка затлар керә алмыйлар.

3.5. Киңәшмәнең рәисе һәм рәиснең урынбасары, Киңәшмәнең беренче утырышында, Киңәшмә әгъзалары саныннан, ачык тавыш бирү юлы белән, әгәр дә алар өчен Киңәшмә әгъзаларының яртысыннан күбрәге тавыш биргән очракта сайланалар. Киңәшмәнең рәисен һәм рәиснең урынбасарын сайлау турында карар Киңәшмә утырышы беркетмәсе белән раслана.

Киңәшмәнең рәисен һәм рәиснең урынбасарын вазифадан азат итү, Идарә башлыгы мөрәҗәгате буенча, ә шулай ук аларның шәхси гаризалары буенча яки Киңәшмә әгъзаларының биштән бере тәкъдиме буенча карала.

Аның өчен, Киңәшмә әгъзаларының яртысыннан күбрәге тавыш биргән очракта, карар кабул ителгән дип санала.

3.6. Киңәшмә әгъзасының вәкаләтләре түбәндәге очракларда туктатыла:

Киңәшмә катнашмасыннан чыгар өчен үзе гариза язу;

сәламәтлеге буенча Киңәшмә эшендә катнашырга сәләтле булмау, Киңәшмә эшчәнлеген үзе бетерү яки башка сәбәпләр булу;

аңа карата хөкемнең гаепләү карары көчкә керү;

аны, гамәлгә кергән хөкем карары нигезендә, эшкә сәләтсез яки билгесез юк булган дип тану;

этика нормаларын тупас бозу – утырышта катнашкан Киңәшмә әгъзаларының гомуми саныннан, күпчелек тавыш бирү юлы белән, кабул ителгән Киңәшмә карары буенча;

Россия Федерациясе гражданлыгын бетерү;

Киңәшмә утырышы эшендә системалы рәвештә (3 мәртәбәдән күбәк) ихтирамлы сәбәпсез катнашмау;

Киңәшмә рәисе һәм рәиснең урынбасары биргән йомышны системалы рәвештә ( 2 мәртәбәдән күбәк) ихтирамлы сәбәпле үтәмәү;

аны Россия Федерациясенең дәүләт гражданлык хезмәте вазифаларын, Россия Федерациясенең дәүләт вазифаларын, Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең башка субъектларының дәүләт вазифаларын, муниципаль һәм муниципаль хезмәт вазифаларын алмаштырырга билгеләү;

аның белән икеләтә гражданлык алу.

3.7. Иҗтимагый киңәшмәдә әгъзалылык бетү, Киңәшмә әгъзасыннан язмача гариза алу яки рәис, рәиснең урынбасары тәкъдим итү нигезендә, ә шулай ук бу кагыйдәмәнең 3.6. пунктында күрсәтелгән очраклар ачыкланган очракта, Идарә башлыгы карары белән тәңгәл килеп тормышка ашырыла.

Сәламәтлеге буенча Киңәшмә эшендә катнашырга сәләтле булмау, аңа карата хөкемнең гаепләү карары көчкә керү, Россия Федерациясе гражданлыгын бетерү очрагында Киңәшмә әгъзасы, бу очраклар турында Киңәшмәнең рәисенә яки рәиснең урынбасарына әйтергә тиеш.

3.8. Киңәшмә әгъзасының вәкаләтләрен туктатып тору, рәиснең тәкъдиме нигезендә, Идарә башлыгы карары белән , түбәндәге очракларда булдырыла:

аңа, Россия Федерациясенең җинаять- процессуаль кануннар белән билгеләнгән тәртиптә, җинаять эшләүдә гаепләү күрсәтү;

аңа административ кулга алу рәвешендә административ җаза бирелү;

аның кандидат рәвешендә дәүләт хакимиятенең кануннар чыгаручы әгъзасында, җирле үзидарә әгъзасында сайланма урынга кандидат рәвешендә теркәлүе, сәяси партия кандидатының вәкаләтле вәкиле яки ышанычлы заты булуы, ә шулай ук Россия Федерациясендә референдус уздыру буенча инициативалы төркем катнашмасына керү.

**4. Иҗтимагый киңәшмә әгъзаларының хокуклары һәм бурычлары.**

4.1. Киңәшмә әгъзасы хокуклы:

федераль канунар белән тәңгәл килеп, дәүләт серен тәшкил итә торган мәгълүмат, шәхси мәгълүмат һәм чикләнгән рөхсәтле мәгълүмат куллану сәбәпле рөхсәте чикләнә торган чаралардан кала, Идарә инициативасы буенча үткәрелә торган барлык чараларда( утырыш, киңәшмә, “ түгәрәк өстәл” һ.б.) катнашырга;

инициативалы тәртиптә Киңәшмәгә анализ язуларын, докладлар һәм башка мәгълүмати-анализ материалларын әзерләргә һәм юнәлтергә;

Киңәшмә рәисе аркылы, Киңәшмә эшчәнлеге планына һәм аның утырышларын уздыру тәртибенә тәкъдимнәр кертергә;

Көн тәртибендә булган сорауларны карау өчен, Киңәшмә утырышына чакырыла торган кандидатлар буенча, тәкъдимнәр кертергә;

Киңәшмә катнашмасыннан чыгарга.

4.2. Киңәшмә әгъзасы бурычлы:

Киңәшмә рәисе белән бирелгән йомышларны үтәргә;

бу кагыйдәнамә белән каралган Киңәшмә эшчәнлегенең тәртибен белергә һәм үтәргә;

Киңәшмә утырышларында шәхси катнашырга;

аңа салынган вазифаларны башкару өчен, Киңәшмә белән оештырыла торган эксперт, эш төркемендә, комиссияләр, башка эш әгъзалары эшчәнлегендә катнашырга;

## 5. Киңәшмәнең эш тәртибе

5.1. Киңәшмә үз эшчәнлеген, Киңәшмә рәисе тәкъдим ителә торган, Киңәшмәдә раслана торган планнар һәм программалар белән туры китереп оештыра.

5.2. Киңәшмә эшен планлаштыру, Киңәшмә әгъзалары , Киңәшмә рәисе һәм башкарма әгъза тәкъдиме нигезендә тормышка ашарыла.

5.3. Киңәшмә утырышы кварталга бер тапкыр уздырыла. Киңәшмә утырышында кабул иткән карарлар беркетмә белән рәсмиләштерәләр.

Киңәшмә утырышлары шулай ук, 2013 елның 29 мартыннан 214 номерлы “Башкарма хакимият әгъзалары карамагындагы иҗтимагый киңәшмә утырышларында тикшерүдән башка кабул ителә алмый торган, Татарстан Республикасының башкарма хакимият әгъзалары белән эшкәртелә торган норматив хокукый актлар һәм башка документлар катнашмасын раслау турында” Татарстан Республикасы Министралар Кабинеты карары белән расланган, башкарма хакимият әгъзалары карамагындагы иҗтимагый киңәшмә утырышларында тикшерүдән башка кабул ителә алмый торган, Татарстан Республикасының башкарма хакимият әгъзалары белән эшкәртелә торган норматив хокукый актлар һәм башка документлар белән карала торган, Идарә белән эшкәртелгән норматив хокукый акт проектларына Киңәшмә нәтиҗәсен бирү максаты белән, Идарә инициативасы буенча уздырыла һәм норматив хокукый актлар Татарстан Республикасының Идарәнең Юстиция министрлыгына билгеләнгән тәртиптә юнәлтелә.

5.4. Киңәшмә утырышы, әгәр дә анда Киңәшмә әгъзаларының өчтән икесеннән дә ким булмаса хокуклы дип санала. Киңәшмә әгъзасы утырышта шәхси катнаша алмаган очракта, көн тәртибенә кертелгән сораулар буенча, үзенең тавышын һәм үзенең хөкемен, Киңәшмә рәисенә яки аның урынбасарына яки Киңәшмәнең җаваплы сәркатибенә белдереп, язмача, факсимиль яки электрон почта аша Киңәшмәнең башка әгъзасына тапшырырга хокуклы.

Киңәшмә белән, бу Кагыйдәнамәнең 5.3. пунктының икенче кызыл юлында күрсәтелгән, норматив хокукый акт проектларын карау, Идарә белән аларны Иҗтимагый киңәшмәгә җибәргән көннән алып, 10 көн эчендә үтәлә. Шул ук вакытта Киңәшмәнең бәяләмәсен бирү максаты белән, алар буенча сайлауны уздыру, Киңәшмәнең бөтен әгъзаларыннан сорау алып, читтән торып тавыш бирү юлы белән уздырылырга мөмкин. Сораунамәнең нәтиҗәләре, Киңәшмә рәисе, ул булмаган очракта –аның урынбасары белән раслана торган, беркетмәгә теркәлә.

Андый тавыш бирү почта, телегра, телетайп, телефон, электрон яки документларны алганда һәм биргәндә аутентиклыкны тәэмин итә торган һәм аларны документаль рәвештә раслый торган, башка элемтә аша документлар алмашу юлы белән уздырылырга мөмкин.

Читтән торып тавыш бирү очрагында рәиснең урынбасарына, барлык Киңәшмә әгъзаларына тәкъдим ителә орган көн тәртибе, норматив хокукый акт проекты юнәлтелә.Алар буенча, утырыш уздыруның вакытына кадәр 7 көннән дә соңармыйча, Киңәшмәнең йомгагы бирелә. Киңәшмә әгъзаларына кирәк булган очракта Идарәдән карала торган норматив хокукый акт проекты буенча өстәмә мәгълүматны сорап алалар.

Иҗтимагый киңәшмәнең карарлары күпчелек тавыш белән кабул ителәләр.

5.5. Киңәшмә утырышларын Киңәшмә рәисе уздыра, ә ул булмаган очракта - Киңәшмә рәисенең урынбасары.

5.6. Аның өстенә йөкләнгән максатлар, мәсьәләләр, вәкаләтләр белән туры килеп, Киңәшмә белән кабул ителә торган карарлар, тәкъдим рәвешендә булалар һәм кызыксынучы затларга Киңәшмә утырышының беркетмәсеннән өземтә рәвешендә яки Киңәшмә карары буенча башка ысул белән җибәреләләр.

5.7. Киңәшмә эшчәнлеге турында мәгълүмат интернет челтәрендә Киңәшмә сайтында яки Идарә сайтында өстәмә бит булып урнаштырыла.

5.8. Киңәшмә рәисе:

Киңәшмә эшчәнлеген гомуми җитәкли;

Киңәшмә утырышын алып бара;

Киңәшмә әгъзаларының тәкъдимнәре нигезендә Киңәшмәнең эш планын әзерли, ә шулай ук аларга үзгәрешләр кертә һәм аларны Киңәшмәгә раслау өчен тәкъдим итә;

Киңәшмә утырышын оештыра;

Киңәшмәнең утырышының көн тәртибен раслый;

Киңәшмәнең тәкъдимнәрен, беркетмәләрен һәм башка документларын раслый;

Киңәшмә уздыруның вакытын һәм урынын билегли;

Киңәшмә эшчәнлеге, аның өстенә йөкләнгән максатлар, мәсьәләләр чикләрендә, Киңәшмә әгъзаларына бурычлар бирә;

Киңәшмә исеменнән сораунамәләрне, тәкъдимнәрне, җавапларны, аңлатмаларны һәм мөрәҗәгатьләрне имзалый;

Киңәшмә эшчәнлеген тәэмин итә торган, башка бурычларны үти.

5.9. Киңәшмә рәисенең урынбасары:

рәиснең рәсми рәвештә булмаган очрагында, Киңәшмә рәисенең бурычларын үти;

Киңәшмә утырышын әзерләүне оештыра;

Киңәшмә утырышының көн тәртибен әзерли һәм аны Киңәшмә рәисенә раслауга бирә;

Киңәшмә рәисе бурычы буенча, Киңәшмә эшчәнлеген тәэмин итә торган, башка бурычларны үти.

5.10. Киңәшмәнең җаваплы сәркатибе:

утырышларга материаллар һәм карарлар проетларын әзерли;

Киңәшмә әгъзаларына Киңәшмә уздыру вакыты һәм урыны турында, көн тәртибе турында әйтә, кирәкле мәгүлүматлар белән тәэмн итә;

Киңәшмәнең һәм башкарма әгъзаның оештырма үзара булышуын тәэмин итә;

Киңәшмә эшчәнлеген документаль-техник яктан тәэмин итә;

Киңәшмә утырышларының беркетмәләрен рәсмиләштерә һәм кабул иткән карарларның үтәлүен тикшерә;

Киңәшмә утырышының көн тәртибен төзүдә катнаша.

5.11. Киңәшмә әгъзалары Киңәшмә утырышларында фикерләшүгә сорауларны әзерләү өчен, эш, экспертлар һәм башка эш төркемнәренә берләшә алалар, материалларны әзерләү өчен, Киңәшмә рәисе урынбасарын кисәтеп, Киңәшмә катнашмасына кермәгән белгечләрне чакырырга мөмкин.

5.12. Киңәшмә карары буенча, Киңәшмә утырышларына, карала торган сораулар буенча кирәкле мәгълүматлар һәм нәтиҗәләр бирү өчен, башкарма әгъза вәкилләре, коммерцияле булмаган оешмалар, фәнни оешмалар,экспертлар һәм башка белгечләр чакырылырга мөмкин.

5.13. Киңәшмәгә каралу өчен бирелә торган материаллар, Киңәшмә рәисе урынбасарына, Киңәшмә утырышы билгеләнгән көнгә кадәр 10 көн элек бирелергә тиеш. Материалларны соңарак бирү очрагы Киңәшмә рәисе яки аның урынбасары белән яраштырыла.

5.14. Киңәшмә эшчәнлеген техник яктан тәэмин итү һәм оештыру Идарә өстенә ята.